КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 июль г.Казань № 617

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында» 2016 ел, 17 март, 148 нче карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында» 2016 ел, 17 март, 148 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 30 апрель, 271 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1061 нче; 2017 ел, 24 апрель, 244 нче; 2017 ел, 22 сентябрь, 708 нче; 2018 ел, 26 апрель, 295 нче; 2018 ел, 19 сентябрь, 799 нчы; 2019 ел, 21 март, 198 нче; 2019 ел, 8 май, 386 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып) расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә теркәлгән кушымтага, аңа түбәндәге эчтәлекле 25 нче пункт өстәп, үзгәреш кертергә.

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «25. | Казан | Волгоград | 2 | 51 | 5 157,0 | 234 862,2 | 01.07.2019 – 31.12.2019». |

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин